КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 23 сентябрь г.Казань № 907

2022 елга Татарстан Республикасы карамагындагы «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус атамалары булган гомуми белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2022 елга Татарстан Республикасы карамагындагы «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус атамалары булган гомуми белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны;

2022 елга Татарстан Республикасы карамагындагы «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус атамалары булган гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү күләменә һәм аларда балаларны карап тотуга карата төзәтү коэффициентларын.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга Татарстан Республикасы карамагындагы «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус исемле гомуми белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2020 ел, 25 сентябрь, 735 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 23 сентябрь, 907 нче
карары белән расланды

2022 елга Татарстан Республикасы карамагындагы «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус атамалары булган гомуми белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар

| Гомуми белем бирү оешмасының төре | Хезмәт күрсәтүдән файдаланучыларның категорияләре | Территориаль дислокациясе | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, 1 елга сум |
|---|---|---|---|
| «Кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус атамалары булган гомуми белем бирү оешмалары | интернатта яши торган тәрбияләнүчеләр | шәһәр җире | 161 791 |
| | | авыл җире | 166 265 |
| | интернатта яшәми торган тәрбияләнүчеләр | шәһәр җире | 74 386 |
| | | авыл җире | 75 183 |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 23 сентябрь, 907 нче
карары белән расланды

2022 елга Татарстан Республикасы карамагындагы «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус атамалары булган гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү күләменә һәм аларда балаларны карап тотуга карата төзәтү коэффициентлары

| Т/с | Гомуми белем бирү оешмасының исеме | Төзәтү коэффициенты |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | «Советлар Союзы Герое Хәсән Заманов исемендәге Актаныш кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,132447 |
| 2. | «Павел Алексеевич Карпов исемендәге Болгар кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,125303 |
| 3. | «Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллин исемендәге Бөгелмә кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,202650 |
| 4. | «Советлар Союзы Герое Николай Волостнов исемендәге Васильево кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,168379 |
| 5. | «К.С.Байкиев исемендәге Икшермә кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,234728 |
| 6. | «Советлар Союзы Герое Илдар Маннанов исемендәге 82 нче кадет мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,310876 |
| 7. | «Советлар Союзы Герое Никита Кайманов исемендәге Кадет мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,343118 |
| 8. | «Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов исемендәге Казан кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,228308 |
| 9. | «Советлар Союзы Герое Михаил Алексеевич Чирков исемендәге Кама Тамагы кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,167305 |
| 10. | «Советлар Союзы Герое генерал-полковник Василий Николаевич Гордов исемендәге Минзәлә кадет интернат | 1,187612 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 11. | «Советлар Союзы Герое Гани Сафиуллин исемендәге Идел буе федераль округының Татарстан кадет корпусы» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,194455 |
| 12. | «Генерал-майор Владимир Аверкиевич Хапаев исемендәге Тәтеш кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,167370 |
| 13. | «Советлар Союзы Герое И.Н.Конев исемендәге Чирмешән кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,175834 |
| 14. | «Советлар Союзы Герое Сергей Евдокимович Кузьмин исемендәге Чистай кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,225572 |
| 15. | «Калкан» полиция кадет мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,363780 |

___